СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

26 сентябрь, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 108 (8120)


Бәясе билгеләнгәнчә

## Өлкәннәрункөнлеге

1 нче октябрь - Халыкара өлкәннәр көне алдыннан район хакимиятендә аерым бер тармак һәм предприятие җитәкчеләре катнашында узган эшче киңәшмәдә бу чараны оештыру һәм үткәрү буенча тәкъдимнәр әйтелде һәм конкрет бурычлар куелды.

Районда өлкән яшьтәгеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән гамәли чаралар күрелә. Аерым алганда, пенсияләр вакытында түләнә, күп кенә социаль - көнкүреш мәсьәләләре дә хәл кылына. Шулай булса да өлкәннәр көне һәм районда 1 октябрьдән 10 октябрьгә кадәр игълан ителгән ункөнлек социаль яклау оганнарының, хезмәт коллективларының, җәмәгатьчелекнең өлкән буын проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән гамәлләрен активлаштырырга тиеш. Иң элек андыйларның йортларын, фатирларын, йорт яны корылмаларын ремонтлатуга, аларга ягулык китертүгә, өй яны бакчаларын эшкәртү, малларына льготалы бәяләрдә азык кайтартуга игътибар бирелергә тиеш. Мөмкинлектән чыгып матди ярдәм дә күрсәтергә кирәк. Җирле бюджеттан бу максатларга акча средстволары бүлеп биреләчәк. 1 октябрьдән 5 сенә кадәр пенсионерлар чәчтараш, мунча хезмәтеннән бушлай, аяк киеме төзәтү мастерское хезмәтләреннән ташламалы тәртиптә файдалана алачаклар. Хезмәт ветераннарыннан 20 кешегә республика санаторийларына путевкалар бирелде, 30 кеше НГДУның, чикләнгән җаваплылыктагы «Татнефть - Норлатнефтеразведка» җәмгыятенең, Иске Чаллы участок шифаханәсенең дәвалау - савыктыру комплексларында бушлай дәвалану курсы үтә алачак. Район хакимиятендә эшләнгән мәдәни программа кысаларында Чулпан картлар йортына барып үзешчән сәнгать көчләре концерты кую һәм бүләкләр өләшү, урыннарда ял кичәләре уздыру да каралган. 1 октябрьдә иртән район мәдәният йортында өлкәннәр көне шәһәр һәм райондагы төрле категория өлкәннәр, район, крестьян һәм фермер хуҗалыклары җитәкчеләре, җирле үзидарә Советлары, тармак предприятиеләре җитәкчеләре катнашында билгеләп үтеләчәк. Ул чарада республиканың вице - премьеры И.К.Хәйруллин, кайбер министрлык һәм ведомство җитәкчеләре катнашуы көтелә. Өлкәннәргә игътибарны көчәйтүнең социаль программасы өлкәсендә башкарылган эшләргә йомгак ясалачак, кызыксындырган сорауларга беренче затларның җавапларын ишетергә мөмкин булачак бу очрашу һичшиксез истә калырлык булыр. Шул ук көнне шәһәрдәге 5 кафе һәм ашханәдә хәйрия ашлары оештырылачак, пенсионерларга азык - төлек җыелмалары тапшырылачак.

Киңәшмәне хакимият башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова һәм социаль яклау идарәсе башлыгы Л.Н.Дилмөхәммәтова алып бардылар.



Вазыйх-Бөек Ватан сугышы чоры баласы.«Җиңү» сүзен ишеткәндә сугышның ни дә, җиңүнең нинди әһәмияткә ия сүз булуын тәгаен аңларлык хәлдә иде инде ул.Хезмәт төшенчәсенең мөһимлеген дә шушы елларда ачык аңлады малай:эшләргә кирәк. Бары эш белән генә ярымҗимерек авылны рәткә кертеп, фронтта һәлак булган ата-бабалары урынына басып эшләп кенә аларның балаларын аякка бастыру мөмкин булачак.Даими эшләү, алны-ялны белми хезмәт кую-шушы елларда егет өчен төп принципка әверелде.Шунысы үзенчәлекле,Вазыйх бүгенге көнгәчә шул принципка тугъры.Шофер булып эшли ул.1964 нче елда ничек «ГАЗик» руле артына утырган булса, бүген дә һаман машинада. «ГАЗ»ны да йөртте,ЗИЛны да. Хәзер инде «КамАЗ»да. Шушы еллар эчендә күпме юл үтүен, машина әрҗәсендә күпме йөк күчерүен санасаң икән...Мөмкин нәрсә түгел бу. Шушы чорда бер-бер артлы туган 4 бала үсеп җитеп, таралыштылар,хатыны Зәкия пенсиягә чыкты. Вазыйхның да чәчләренә чал кунды. Әмма моңа карап кына йөрәге картая дип санамый әле ул.Көн саен көр кәеф белән эшкә китә.«КамАЗ»ына утыра да яшьләр белән узыша-узыша басудан ындыр табагына ашлык кайтара,буш вакытларында элеваторга юл тота.

**Рәсемдә: «Киекле» КХАсы шоферы Вазыйх Халитов.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## ИГЪТИБАР:

**12 октябрь көнне Норлат аэропортындагы сабантуй мәйданы норлатлыларны һәм районның авыл эшчәннәрен «Уңыш - 97» бәйрәменә җыя.**

*Кадерле якташлар!*

*Бу көнне сезне чын ял, күңел ачу чараларын эченә алган бәйрәм көтә. Анда нәкъ язгы сабантуйдагы төсле атлар парады, ат чабышлары, һәртөрле спорт ярышлары (моңарчы булганнарына биеклеккә сикерү, 100 метрга йөгерү дә кертелә). Спорт - күңел ачу уеннары (капчык киеп, йомырка кабып, көянтә белән йөгерү, капчык сугышы, багана башына менү һ.б.) булачак.*

*Ат чабышларын быел зур, мәртәбәле итеп «Татнефть» АҖсе оештырачак, көчләрен сынарга нефть районнарыннан да иң җитез чаптарлар килергә әзерләнә. Нефтьчеләр шулай ук автокросс һәм мотокросс үткәреп тә бәйрәмдәгеләрне шаккатырырга җыеналар. Иң дулкынландыргычы - милли көрәш тә тамашачыларны күп җыяр дип уйлыйбыз.*

*Бәйрәм үтәсе мәйдан сезне күркәм бизәлеше, мул сәүдә рәтләре (авыл хуҗалыгы ассоциацияләре, оешма, предприятиеләр дә сату итәчәк), бай концерт программасы белән дә таң калдырырга җыена. Бу көнне республика татар эстрадасы йолдызлары, җирле талантларыбыз район авыл хуҗалыгы алдынгыларын хөрмәтләп чыгыш ясаячак.*

*Әлбәттә, кыр батырлары, урак алдынгылары бәйрәмнең иң кадерле, хөрмәтле кунаклары булачаклар. Сез бу көнне иң алдынгы хуҗалыклар, иң фидакарь игенчеләр исемен ишетерсез, аларны олылауның шаһиты булырсыз.*

*Нәни норлатлылар карамагында бу көнне «Балалар шәһәрчеге» эшләячәк.*

*Бәйрәмгә әзерләнегез, җилдәй җитез аргамакларыгызны ярышка иярләгез, якташлары өчен сөенеп тамаша кылырга кунаклар чакырыгыз!*

**Кунакчыл Норлат җиренә бәйрәм килә, муллык бәйрәме, Уңыш бәйрәме килә.**

## АҢЛАШЫП ЭШЛӘҮ ӘЙБӘТ

Яз - җәй - көз - авыл хуҗалыгы эшчәннәре өчен кылны кырыкка ярыр чак. Шуңа бу чорда бер техниканы бишкә бүлергә җитәсең, юк кына тоткарлыктан эш тукталса бөтенләй кәеф кырыла, инде шундый чакларда ярдәм кулы сузучы булса кәеф бермә - бер үзгәреп, эш тернәкләнеп китә.

Бәхеткә, безнең «Родина» КХАсына шундый сизгер һәм ярдәмчел шефлар туры килде. Норлат геофизик эшләр идарәсе быел безгә шундый ярдәмне күп күрсәттеләр: кирәк чакта ягулык белән дә, техника белән дә, булыштылар, азык әзерләү чорында ике силос траншеясы ясап бирделәр, аннан килеп яфрак азык әзерләштеләр. Идарә начальнигы В.Г.Наумов һәр үтенечебезгә сизгер, игътибарлы булды.

Ә менә «Агрохимсервис» АҖсе безгә шефлык та итми инде югыйсә. Әмма коллективның быел авыл эшчәннәренә туры карашы, алар белән кулга - кул тотышып эшләвен без үзебезнең мисалда ачык күрдек. Җәмгыять ашлама белән тәэмин итүдә, үсемлекләрне саклауда, үзеннән торганның һәммәсен эшләде, кирәк чакта техника белән дә ярдәм итте. Җәмгыять директоры Х.Х.Морадыймов эшчеләренең хезмәте сыйфатын үзе килеп карый, хуҗалыкка киңәшләрен дә биреп китә иде. Шуңа да телгә алынган коллективларга, аларның җитәкчеләренә родиналылар исеменнән олы рәхмәтебезне җиткерәсебез килә. Киләчәктә дә шулай аңлашып - ярдәмләшеп эшләрбез дип ышанабыз, авыл кешесенә мондый игътибар һәм булышу тансык та, файдага да бит.

**Х.ХӘМИДУЛЛИН,**
**«Родина» КХАсы рәисе.**

## ТУҢГА СӨРҮ НИЧЕК БАРА?

***Район хуҗалыкларында 24 сентябрьгә туңга сөрү планының үтәлеше (процентларда).***

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Дуслык» | 78 | «40 лет Победы» | 57 |
| «Таң» | 77 | «1 нче Май» | 57 |
| Синдряков исем . | 72 | Хафизов исем | 55 |
| Мичурин исем. | 72 | «Алга» | 55 |
| «Чирмешән» | 69 | МСО ярд. хуҗ | 55 |
| «Киекле» | 69 | Агробанк ярд.хуҗ | 53 |
| «Рассвет» | 69 | «Төрнәс» | 52 |
| М.Җәлил исем. | 67 | «Заря» | 52 |
| Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 67 | «Кондырча» | 51 |
| «Якты Күл» | 67 | «Үрнәк» | 48 |
| «Родина» | 62 | «Әлмәт» | 45 |
| «Заветы Ильича» | 62 | «Татарстан» | 43 |
| Кузнецов исем. | 62 | «Игенче» | 40 |
| «Агрохимсервис ярд. хуҗ. | 62 | Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 36 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 58 | «Комбайн» | 34 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 58 | **Район буенча** | **57** |

Туңга сөрелгән мәйданнар соңгы биш көндә 4850 гектарга ишәйде. Бу эш ярыйсы гына көйле барган хуҗалыкларда эшкәртеләсе мәйданнар азая барганда моны аңларга булса да, көн саен 150дән артык трактор, шул исәптән 25 К- 700 эшләп торганда бу темп һич тә канәгатьләнерлек түгел әле. Билгеле, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенә бирелә торган оператив мәгълүматларның ни дәрәҗәдә объективлыгы турында сүз йөртергә алынмыйбыз. Әмма эш нәтиҗәләрен чагыштырып караганда бик искитмәле саннарга тап буласың. Әйтик, «Киекле» һәм Хафизов исемендәге хуҗалыкларның икесендә дә туңга сөрүдә уникешәр берәмлек техника, шул исәптән беренчесендә ике, икенчесендә бер К - 700 тракторы катнаша, ике сменада эшләтелә торган тракторлар саны да бер чама ук. Әмма «Киекле»дә соңгы биш көндә 480 гектар җир сөрелсә, икенчесендә бу күрсәткеч моның яртысы чамасы гына. Димәк, я техниканың җитештерүчәнлеге түбән, я тракторларның кайсылары сабансыз гына йөри булып чыга түгелме соң?! Яки менә «1 нче Май» белән нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларының икесендә дә дүртәр техника эшли, шул исәптән беренчесендә К - 700дә бар, әмма нәтиҗәләр төрлечә - беренчесендә биш көндә сөрелгән җир ике тапкыр кимрәк. Уйланырлыкмы? Ничек кенә әле. Кузнецов исемендәге һәм «Татарстан» хуҗалыкларын чагыштырсаң да шулай ук искитмәле саннарга юлыгасың. Һәм мондый мисалларны шактый күп китерергә булыр иде.

Ә инде техниканың ике сменада файдаланылу - файдаланылмавы турында мәгълүматларны ничек бар шулай кабул иткәндә «Заря», «Әлмәт», «Кондырча», «Төрнәс», «Комбайн», «Үрнәк» һәм кайбер башка хуҗалыкларда төнге сменада санаулы техника гына эшли, я бөтенләй булмый. Ә бит ул хуҗалыкларның берсендә дә туңга сөрү планының үтәлеше белән мактанырлыклары юк әле. Район буенча да ике сменада файдаланыла торган техника саны туксанга да җыелмый. Болай булса туңга сөрү кебек җаваплы эшнең туңнарга калу куркынычы зур.

Кайсы көннәрдә техниканың азрак чыгуына объектив сәбәпләр булса да, эшкә тартылган агрегатларның җитештерүчәнлеге түбән булуны исә берничек тә аклап булмый. Механизаторларны эшкә туплау, аларның хезмәт нәтиҗәләре белән кызыксынуына ирешү чараларын күрү зарурлыгы көн кебек. Әгәр дә агрегатлар эшкә соң тотынып, кырдан иртә кайта, кайчагында ягулык салу яки ашап алу өчен дә басудан авылга трактор куарга туры килә икән, андый чакта нинди югары җитештерүчәнлек турында сүз булырга мөмкин ди. Ә мондый мисаллар шактый әле.

# Сезнең иминият полисыгыз



***Газета укучыларыбызның мәҗбүри медицина страхованиесе системасы турындагы сорауларына Октябрь территориаль шифаханә кассасы җавап бирә.***

**Норлатта пропискада торып, башка районда эшләүчеләр иминият полисын кайдан алырга мөмкиннәр?**

Норлатта пропискадагылар кайда эшләүләренә карамастан иминият полисын Октябрь территориаль шифаханә кассасыннан ала алалар. Ә инде пропискада башка шәһәрдә яки районда булып та Норлатта эшләүчеләргә полис тору урыннарында биреләчәк.

**Норлат кешесе башка шәһәргә командировкага барганда иминият полисын үзе белән алырга тиешме?**

Иминият полисын күрсәтмичә бары тик ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме генә алырга була. Калган башка очракларда Татарстан Республикасының барлык территориясендә дә мәҗбүри медицина страхованиесе кысаларындагы медицина ярдәме иминият полисы булганда гына бушлай күрсәтелә. Әгәр дә сез Татарстанның башка шәһәрендә планлы рәвештә шифаханәгә кереп ятарга булсагыз, медицина учреждениесе-Октябрь үзәк район шифаханәсеннән бирелгән юллама һәм территориаль шифаханә кассасыннан гарантия хаты таләп итәргә хаклы.

Безнең район һәм Татарстан гражданнарына Татарстаннан читтә күрсәтелә торган медицина хезмәтен оештыру һәм аңа түләү Республика сәламәтлек саклау министрлыгы белән килештерелгән тәртиптә Республика шифаханә кассасы тарафыннан башкарыла.

**Отпускыда вакытта башка шәһәрдә авырып китә калсаң Октябрь территориаль шифаханә кассасы тарафыннан бирелгән полис буенча хезмәт күрсәтәчәкләрме?**

Әйе, Россия Федерациясенең теләсә кайсы почмагында.

**Территориаль шифаханә кассасы иминият полисын сезнең туганнарыгызга бирүдән баш тартырга хаклымы?**

Юк. Иминият полислары карт кешеләрнең, урында ятучы сырхауларның һәм инвалидларның полисларын туганлыкларын яки опекунлыкларын раслаучы документларны күрсәткәч аларның туганнары яки опекуннары кулына бирелә.

**«Ашыгыч ярдәм» авыруның кулында полисы булмаган очракта аңа ярдәмгә бармаска хаклымы?**

Россия Федерациясенең барлык территориясендә дә ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме сезнең мәҗбүри медицина страхованиесе полисыгыз булу - булмауга карамастан бюджет средстволары исәбенә бушлай күрсәтелә. Ашыгыч һәм кичектергесез ярдәм килгән өчен авырулардан акча таләп итүнең барлык очраклары турында да район үзәк шифаханәсенә, ашыгыч медицина ярдәме җитәкчелегенә яки территориаль шифаханә кассасына хәбәр итәргә кирәк.

**Норлатта бирелгән иминият полисы белән Россиянең башка шәһәрләрендә медицина ярдәме алырга мөмкинме?**

Әйе. Читтән килгән кешеләр Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан дәвалау - профилактика учреждениеләрендә Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы юлламасы буенча үткәрелә торган һәм түләү мәсьәләсе Республика шифаханә кассасы белән килештерелгән планлы дәвалау үткәндә планлы медицина ярдәмен мәҗбүри медицина страхованиесе средстволары исәбенә алалар. Бу очракта планлы медицина ярдәме өчен авыру дәваланган медицина учреждениесе тарафыннан бирелгән реестр һәм счет буенча территориаль шифаханә кассасы түләячәк.

Иреклe рәвештә түләүле дәваланган өчен, медицина хезмәте реестрларысыз квитанция һәм счетларны территориаль шифаханә кассасы кабул итми.

Планлы рәвештә шифаханәгә кереп яту өчен полистан тыш җирле сәламәтлек саклау органы тарафыннан бирелгән юлламаны һәм мәҗбүри медицина страхованиесенең территориаль фондыннан гарантия хатын да күрсәтергә кирәк.

**Кеше страхование компаниясен үзе сайлап ала аламы?**

Әйе. Моның өчен иминият полисы алган территориаль шифаханә кассасына мөрәҗәгать итеп үзегезнең полисыгызны яңабаштан теркәтергә кирәк.

**Иминият полисы буенча нинди төр медицина ярдәме алып була?**

- Татарстан Республикасының амбулатор - поликлиника һәм стационар медицина учреждениеләрендә балаларга һәм олыларга күрсәтелә торган барлык төр медицина ярдәмен;

- халыкка табиб рецепты буенча билгеләнгән тәртиптә бушлай яки 50 процентлы ташлама белән бирелә торган дару средстволары һәм медицина багъланышлы әйберләр өчен түләүдәге чыгымнарны финанслау рәвешендә дару хезмәте;

- Дәвалау Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы юлламасы буенча үткәрелгән һәм түләү мәсьәләсе Республика шифаханә касссасы белән килештерелгән очракларда Татарстаннан читтәге дәвалау - профилактика учреждениеләрендә медицина хезмәте.



## Эштә дә, тормышта да

Аларны бергә еш очратасың. 15 еллап инде бер оешмада-»Норлатнефть» НГДУсының торак-коммуналь хуҗалыгында янәшә эшлиләр алар. Самарада профтехучилище тәмамлап, буяучы һөнәренең серен өйрәнеп, эштә ныгып өлгергән Галина Ивановна бирегә байтак алда килгәнлектән, яшь хезмәттәшен күп нәрсәгә өйрәтте. Тәҗрибәсе, белеме өстенә, гаҗәеп пөхтәлеге, ноктасына-җөенә кадәр җиренә җиткереп эшләү гадәте булган Галина Ивановна остаз буларак та таләпчән һәм кырыс иде: өйрәнгәндә үк үзенә һәм кешегә ошарлык эшләргә күндерде. Мөгаен, шуңадыр да, Сәрия Гамилевна бу авыр эштә сәнгатьтәгечә зәвык, пөхтәлек иң мөһиме икәнлеген беренче чиратта төшенде һәм гомере буе онытмаска тырышты. Соңрак, инде үзе рәсеме «Норлатнефть» НГДУсының мактау тактасында тотырлык эш остасы булып җитешкәч тә, өйрәнгән кыйбласын җуймады. Шулай да Галина Ивановна белән киңәшүдән тартынмады. Ни дисәң дә, бригадада иң оста плитәче, иң таләпчән буяучы, иң пөхтә обойчы саналган тәҗрибәле оста сүзе беркайчан комачауламый иде шул. Ә бер, янәшә хезмәттә килешеп эшләү зур нәрсә ул. Шуңа да НГДУ ЖКХсы заявкалар нигезендә шәхси фатирларга ремонт ясау хезмәтен керткәч, нәкъ менә Вазюкова бригадасы кызларының эшләвен сораучылар аз түгел иде. Озак еллар шулай торак, балалар бакчасы, профилакторий, административ биналар ремонтлап-бизәп остарган куллар, әлбәттә, һичкайчан сынатмадылар, кызлар үз гомерләрендә рәхмәтне аз ишетмәделәр.

Хатын-кызлар арасында шулай бер-берсен аңлау тора-бара чын дуслыкка, гаиләләре белән аралашып яшәүгә китерде. Вазюковларның өч балалы тәртипле, тату гаиләсендә Сәрия җиткән кызы белән һәрчак көтелгән кунак, икесе дә гаҗәеп булдыклы, аш-суга уңган хатын-кызларның көнкүрештә дә булышыр, уртаклашыр сүзләре гел була.

«Норлатнефть» НГДУсы ЖКХсы МПП составына тапшырылгач, биредә ремонт участогы гына калдырылды. Вазюкова һәм Ханипова шул өйрәнгән хезмәтләре, күнгән коллективларыннан күчәргә уйламадылар. Соңгы вакытта алар Андреевкадагы промыселда ремонт эшләре алып бардылар. һәм һәрвакыттагыча, Вазюкова һәм Ханипова кулы тигән һәр җир күзне иркәләрлек булып көлеп калды.

**Рәсемдә: буяучылар Г.И.Вазюкова һәм С.Г.Ханипова.**

## ШЕФЛАР ДА БУЛЫША

**Киекле кооперативлар ассоциациясе**

Хуҗалык шефлары - Норлат автоюллар идарәсе ярдәменнән бик канәгать быел. Урак вакытында ашлык ташуда даими 2 машина эшләп торса, туңга сөрү эшләренә ярдәмгә янә ике тракторчы - Сергей Яллин һәм Анатолий Тайбулатов килде. К - 700 тракторында француз сабаннары белән ике сменада җирләрне туңга сөрәләр алар, бүген алар исәбендә 730 гектар эшкәртелгән мәйдан бар. Егетләр гомер буе җир белән эш иткәннәр диярсең: сыйфатлы, барлык технологик таләпләрне үтәп башкаралар хезмәтләрен.

Хәер, киеклеләрнең үз механизаторлары эшенә дә тел - теш тидерерлек түгел. Марат Хәбибуллин һәм Салават Әхмәтов К- 700 тракторы белән ике сменада шулай ук 500 гектардан артык туңга сөрделәр. ДТ - 75 тракторчысы Касыйм Әштрәпов та көнлек нормасын арттырып үтәп килә.

Шулай күмәк тырышлык белән хуҗалыкта 80 процент мәйданда җирләр туңга сөрелде инде.

**Н.ШАКИРОВ.**

## ИПИНЕҢ КАЙНАРЫ ТӘМЛЕ

Яңа Тумбада соңгы елларда пекарня чынлап торып телгә кергән иде. Иске бинасы таралып бетте диярлек һәм авыл халкын ипи белән тәэмин итү проблемасы алга килеп басачагы көн кебек иде. Бера ипине я Төрнәстән, я Заречныйдан ташып тордылар... Ул арада завод территориясендә яңа пекарня корып куйдылар. Әллә ни искитмәле булмаса да, нык. Мастер Раиса Ивановна Соловьева электр мичен дә үзе карый, ипиен дә үзе пешерә һәм үзе үк сатучы да. Бер куйганда мичкә 70 кирпеч ипи сыя. Биредә аның I һәм II сортлысын да, «Дарницкий» дигәнен дә пешерәләр. Тумбалылар 750 граммлы ак күмәчне бик яратып алалар. Биш ел буе ипи пешереп, Раиса Ивановна бу эшнең күп серләренә дә төшенде, эшен дә күңел җылысын салып башкара.

Үзе шушы авылныкы ул, әмма чирек гасыр Үзбәкстанда гомер иткән. Милли мәсьәләләр катлауланып киткәч туган якларына кайткан. Авылның йөзъяшәрләреннән берсе, 94 яшьлек әнисе белән икәү генә яшиләр. Ул элек тә мастер булган, тик ванналар кою буенча, ә хәзер менә ипи пешерү остасы. Он капчыкларын берүзе күтәреп ташырга, ипине вакытында өлгертү өчен иртә торырга туры килсә дә, эшен ошата ул, яратып башкара. Кулларына мичтән генә чыккан, өсте кызарып киткән, кетердәп торган кайнар ипи тотып чыгып китүче кешеләрнең йөзләрендәге канәгатьлекне күрү дә аңа көн саен яңа рух өсти торгандыр.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

**Кеше һәм аның эше**

# Урман үстерү - яшәү максаты

Кеше үз гомерендә өч нәрсә эшләргә: йорт салырга, агач утыртырга, ул үстерергә тиеш диләр. Михаил Валентинович Кузнецов боларның өчесен дә башкарган инде. Шул исәптән агачны бер генә төп утыртып калмаган, ә аның кул җылысы тигән урманнар гектарлап. Восход урманчылыгы урманчысы Михаил Валентинович - 1 нче класслы, ягъни урманчыларга бирелә торган иң югары дәрәҗәгә ия урманчы.

Михаил Валентинович бу хуҗалыкта 24 ел эшли инде. Техникум бетереп юллама буенча килгән иде. Ярты ел урманчы ярдәмчесе булып эшләде, шуннан соң бүгенгәчә - урманчы. Мирасның әллә ни кызыгырлыгы туры килмәде аңа - агач утыртылмаган мәйданнар күп иде. Чын хуҗаның кайгыртулы карашына мохтаҗ иде ул бушлыклар. Ә менә бүген Восход урманчылыгы - республикада иң яхшылардан.

Урманчылык 11507 гектар мәйданга җәелгән. Монда эшләүче урманчылар Татарстанның Аксубай, Октябрь һәм Чирмешән, Самара өлкәсенең Чаллы Башы районнарында яшиләр, чөнки урманчылыкның чикләре шулай еракларга сузылган. Коллектив та күпмилләтле, әмма бик дус. Кадрларның алмашынуы юк диярлек, еш кына урман обходлары әтисе кулыннан улына күчә.



Восход урманчылыгы Аксубай урман хуҗалыгы урманчылыклары арасында гел беренче урында, еш кына республика Урман хуҗалыгы министрлыгы күләмендә дә призлы урыннарга чыга. Әле менә урманчыларның быел булып үткән съездында да Восход урманчылыгына икенче урын бирелде, ә Михаил Валентинович үзе съездның президиумында утырды.

- Безнең бурыч - урманны саклау һәм ишәйтү, - диде тәҗрибәле урманчы минем белән әңгәмәдә.- Без шулай ук урман байлыкларын кешеләр ихтыяҗы өчен дә бәрәкәтле, әмма һич тә табигатькә зыян салмаслык иттереп файдаланырга тиешбез.

Ә инде ул бурычның ничек үтәлүен эш күрсәткечләре буенча чамаларга мөмкин. Агымдагы елда дәүләт урман фонды яңа үсентеләр утыртылган 48 гектарга ишәйде. Ә М.В.Кузнецов эшләгән чорда андый мәйданнар 1200 гектарга артты. Киләчәктә шаулап утырачак каен, нарат, имән, чыршы урманнары, шулай ук юл буйларына, чоңгыл кырыйларына утыртылган күпсанлы полосалар алар. Ә үсентеләрне әле Михаил Валентинович монда эшли башлаган елларда ук нигез салган 6,6 гектарлы питомниктан алалар.

Урманчылыкта эшләр көйле барсын өчен җитәкчегә бик киеренке эшләргә туры килә. Аның эш көне гадәттә иртән җиденче яртыда башлана һәм кичке караңгыга кадәр сузыла. Йорт - гаилә мәшәкатьләренә шуннан калган вакыт инде. Әле алары да аз түгел. Хатыны белән бергәләп өч бала үстерделәр алар. Кызлары хәзер табиблыкка укыйлар, төпчекләре - унберенче класста. Йортта да эш җитәрлек. Әле ярый Иске Чаллыда табигый газ кертелгәнгә биш - алты ел инде.

Урманчылык җирле хуҗалык белән дә тыгыз элемтәдә эшли, мәктәп, авыл халкы белән дә дуслыклары зур. Кирәк чакта бер - берсенә бик теләп ярдәмгә киләләр.

Табигатьне саклау бурычыннан тыш урманчылыкка башка мәшәкатьләр дә күп өстәлә. Дару - техник чаралар җыюны гына алыйк. Гадәттә, бу эш белән нигездә мәктәп балалары шөгыльләнә. Урманчылык себерке бәйләү, мунча мунчаласы, мунчала пумала ясау, төрле зурлыктагы буралар бурау кебек халык куллануы товарлары чыгару белән дә мәшгуль.


Алары ай саен 30 - 40 миллионлык ясап урнаштырыла. Шул акча барлык ихтыяҗларын капларга, шул исәптән хезмәт хакы түләүгә дә җитеп бара. (Урманчылыкның хезмәт хакы бирүдә бурычы юк). Үзләренең ярдәмче хуҗалыклары да бар. Анда иген үстерәләр, 15 ат тоталар, шуларның уникесен урманчылар җигә.Урманчылыкның тирә - якта бер җылы гаражы - үзе бер горурлык. Механизаторлар техниканы җылыда төзәтә алулары өчен әле дә урманчыга рәхмәт укыйлар.

Әнә шундый кеше ул Михаил Валентинович Кузнецов һәм ул җитәкли торган коллективның эшләре дә күз алдында. Шундый кешеләр кулындагы урманнарыбызның язмышы өчен һич борчылмаска мөмкин.

**З.ЛЕОНТЬЕВА,**
**Аксубай районының «Авыл таңнары» газетасы корреспонденты.**

# Тырышлыклары бушка китми

Хуҗалыкның Гәйтән бригадасына эшнең иң кызу чагында барып чыккан идем. Техника паркында мәш килгән егетләрнең баш күтәрергә дә вакытлары юк. Бригадирның техника буенча ярдәмчесе Владимир Пайгерчев кул астындагы звено егетләренә дә эш күп - ватылып кайткан техниканы тиз арада төзәтеп кырга озатырга кирәк. Володя дәдәй инде икенче елын пенсиядә булса да, эштән туктаганы юк әле. Дөресен генә әйткәндә, аны җитәкчеләр дә, механизаторлар да лаеклы ялга бик җибәрергә теләмиләр. Бөтенесен таба, булдыра ала торган кеше бит ул. Тимерче хезмәтен башкаручы Валерий Ергункинны да техника паркында гына түгел, бөтен авылда оста куллы кеше буларак беләләр. Көпчәген дә ямый, бакыр, кургаш белән ябыштыру серләрен дә белә. Токарь Николай Глушкин әле яшь кеше, шулай да инде тәҗрибә тупларга өлгергән, кергән бер генә заказны да кире бормый. Электр белән эретеп ябыштыручы Сергей Яндуковка техника паркында эшнең гомер буена бетәсе юктыр. Өстенә брезент киемнәрен киеп йөзен кара пыялалы битлеге артына яшерә дә, күзне сукырайтырлык нурлы очкыннар чәчрәтеп эшләвен белә. Эретеп ябыштыручыларның икенчесе Михаил Пайгерчев та алтын куллы оста. Нәрсәгә алынса да җиренә җиткереп башкара. Урак чорында аңа комбайнчылар звеносының тоткарлыксыз эшләвен тәэмин итәргә туры килде. Т- 40 тракторына тагылган күчмә агрегат белән аны хуҗалыкның ике бригадасы басуларында да очратырга мөмкин иде. Кирәк чакта вакыт белән дә санашып тормый.



Бригаданың ындыр табагында да эш кызу булды. Мөдир Геннадий Тихонович Яндуков әйтүенчә, эшне ике - өч сменада оештырганнар. Ә ындыр тагындагы механизмнарның өзеклексез эшләвен тәэмин итүдә механиклар В.М.Терентьев, А.Н.Микуков, В.Г.Герасимовның өлеше зур булган. Сергей Пашин белән Николай Яфонкин электр җиһазларының төзеклеге турында кайгыртучылар. Үлчәүче Ольга Уфимова, склад мөдире Галина Алексеевна Михедерова кырдан кайткан, дәүләткә озатыла һәм келәтләргә салына торган ашлыкның төгәл исәбен алып бару, аларның яхшы сыйфатлы көенә урнаштырылуы турында һәрдаим кайгыртып торалар. Бригаданың төп эшче көчләреннән булган Елена Пайгерчева, Нина Родионова, Раиса Яфонкина, Валентина Григорьева, Людмила Григорьева, Римма Ревенько, Вера Сашина, Галина Морозова ындыр табагында төп авырлыкны үз җилкәләренә алучылар. Укучы балаларга да эш җитәрлек булды быел. Укучылар хуҗалыкка бик теләп булыштылар, диләр. Терлекчелектә эшләүчеләр дә ашлык язмышы өчен көрәштән читтә калмаганнар - вакытлары булганда килеп шактый ук ярдәм иткәннәр. Шоферлар Сергей Осипов, Валерий Уфимов, Фәрит Әхмәтҗанов, Илфат Закиров, «Сельхозтехника» берләшмәсеннән килгән Юрий Макаров һәм башка бик күпләр ашлыкны ташып урнаштыруда шулай ук хәлиткеч роль үтәгәннәр. Пешекче кызлар Александра Яндукова, Татьяна Терентьева һәм Галина Федотова исә бу кызу эш өстендә кырдагыларның да, техникадагыларның да тамакларын туйдырып, күңелләрен күтәреп торучылар һәм алар пешергән тәмле - тәмле ашлар хезмәт кешесенә көч - куәт тә, эшкә дәрт тә өсти.

Хезмәтне оештыруда күп авырлыклар, техниканың тузганлыгы, еш ватылуы аркасында күп тоткарлыклар булса да, игенчеләр бу кызу чорда барыбер үз алларына куелган бурычны намус белән башкарып чыктылар. Ашлык югалтуларсыз җыеп алынды, хуҗалык дәүләткә ашамлык бодае тапшыру буенча күтәренке заданиене уңышлы үтәп чыкты. Хәзер туңга сөрү кебек мөһим эштә дә сынатмыйлар механизаторлар. Алда торган иң зур сынау - шикәр чөгендерен казып алуда да сер бирмәсләр дип ышанасы килә. Ничек кенә авыр булмасын, тырышлыклары барыбер нәтиҗә бирәсен аңлап эшләү бушка китми. Шулай гына була күрсен..

**Җ.ШАКИРОВ,**
**хәбәрче.**
**«Чирмешән» хуҗалыгы.**

**Рәсемдә: Комбайнчы Валерий Ишмуллин һәм ярдәмчесе Евгений Глушкин, шофер Виктор Уфимов уракта дүртенче ел бергә эшләделәр.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

**КИҢӘШ- ТАБЫШ**

***Кадерле хатын- кызлар! Сез үз хокукларыгызны беләсезме?Укыгыз һәм кирәк чакта алардан файдалана да белегез.***

# ХАТЫН-КЫЗЛАР ХЕЗМӘТЕННӘН ФАЙДАЛАНУНЫ ЧИКЛӘҮ ҺӘМ ТЫЮ

Хатын-кызларны авыр хезмәттә файдалану һәм зарарлы хезмәт шартларында эшләтү тыела.(Россия Федерациясе КЗоТының 160 нчы маддәсе).Андый хезмәтләрнең исемлеге СССРның Дәүләт хезмәт комитеты һәм ВЦСПСның 27.07.78 дә кабул ителгән карарына һәм аңа 26.03,87 дә кертелгән үзгәрештә расланган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты республика профсоюзлары белән берлектә өстәмә рәвештә тагын 17.08.92 дә яңа исемлек - «35 яшькә кадәрге хатын - кызларны эшкә алуны һәм күчерүне тыя торган производстволар, профессияләр һәм зарарлы хезмәт шартлары исемлеге»н раслады.

Авыл хуҗалыгында 35 яшькә кадәрге хатын - кызларны агулы химикатлар, пестицидлар һәм дезинфикцияләү чаралары белән эшләргә туры килә торган хезмәттә файдалану (игенчелектә, терлекчелектә, җәнлек үстерүдә) һәм тракторист - машинист, йөк машиналарын йөртүчеләр итеп алу тыела (ТР Министрлар Кабинетының 11.04.91 дә кабул ителгән 158 нче номерлы карары).

Авыл җирендә эшләүче хатын - кызлар өчен 36 сәгатьлек эш сәгате билгеләнә (ТР Министрлар Кабинетының 11.07.91 дә кабул ителгән 158 номерлы карары). Авыл җирендә эшләүче хатын - кызлар өчен айга бер мәртәбә өстәмә ял көне бирелә, ләкин бу көн өчен хезмәт хакы түләнми.(РФ КЗоТы, 163 матдә).

Хатын - кызлар кул белән күтәреп эшли торган хезмәттә булса, күтәрә торган әйбернең авырлыгы, күтәрү сәгатькә ике тапкырдан артмаганда - 10 килограмм, ешрак күтәрергә туры килсә, 7 килограммнан артмаска тиеш: (РФ хөкүмәте карары. № 105, 06.02.93).

Хатын - кызларны, халык хуҗалыгының кайбер тармакларын исәпкә алмаганда, төнлә эшли торган хезмәткә тарту тыела.

Бигрәк тә йөкле һәм 3 яшькә кадәрле баласы булган хатын -кызларны төнлә эшләтү тыела.(РФ КЗоТы, 1621, 162 маддәләр).

Йөкле һәм 3 яшькә кадәрле баласы булган хатын - кызларны ял көннәрендә һәм эш сәгатеннән тыш эшләтү, командировкага җибәрү тыела.

3 яшьтән 14 яшькә кадәрле (инвалид булса, 16 яшькә кадәр) баласы булган хатын-кызлар, үзләренең ризалыгыннан башка, командировкага җибәрелә һәм эш сәгатеннән тыш эшләтелә алмый.(РФ КЗоТы, 162, 163 маддәләр).

# Сак булыгыз: газ

**1 октябрьдән 30 октябрьгә кадәр газ ягулыгыннан куркынычсыз куллану буенча айлык бара.**

Газ белән торак йортларны ягу, газ ягулыгыннан файдалану безнең районда елдан - ел киңрәк колач ала.

Газ ягулыгын кулланганда аның җитешсезлекләре турында да истә тотарга кирәк. Барлык янучан газлар һава белән кушылып шартлаучан катнашма тәшкил итәләр, бу исә аз гына газ чыгып торганда шартлау куркынычы тудыра.

Газ белән эшли торган мичләрнең һәм аппаратлар өслегенең, төтен каналлары һәм газ горелкаларының югары температурасы янгын чыгуга сәбәпче була ала. Бу исә газ белән эшли торган көнкүреш ягу аппаратлары һәм мичләрен эшләгәндә, урнаштырганда һәм эксплуатацияләгәндә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне таләп итә.

Ягу мичләре өчен газ - горелка җайланмалары плитәгә җайланган блокларга куркынычсызлык автоматикасы приборлары белән бергә куелырга тиеш - алар запальникта ялкын сүнгән очракта горелкаларга газ бирүне автоматик рәвештә туктаталар, төтен юллыгында корылу кимегәндә дә газ бирү туктатыла.

Газ белән ягу аппаратлары һәм мичләре төтен юллыкларыннан файдаланганда каналларны даими рәвештә тикшереп һәм чистартып торырга кирәк. Берочтан каналларның техник торышын контрольдә тотуның прогрессив чараларын да куллануны онытмаска кирәк.

Бинада газ исе сизгәндә аны җилләтеп, газ службасын чакырырга, электр уты һәм башка көнкүреш электр җылыткыч приборларын кабызмаска, ачык уттан файдаланмаска кирәк.

Исегездән чыгармагыз: төзек булмаган газ аппаратларыннан куллану аянычлы нәтиҗәләргә һәм кешеләр үлеменә китерә.

**Р.ӘХМӘДИЕВ,**
**73 нче ПЧ ның өлкән инспекторы,**
**эчке служба капитаны.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

*Бикүле авылында яшәүче кадерле әтиебез **Замалетдинов Рәхимҗан Нурижан** улына 25 сентябрьдә 74 яшь тула. Без аны туган көне белән котлыйбыз, алдагы гомерендә сәламәтлек, тигезлек, бәхетле тыныч картлык телибез.*

*Яшәү маягы син безнең өчен*
*Кешелегең белән үрнәк син.*
*Мең - мең рәхмәт тәрбияңә әти*
*Безнең өчен һәрчак кирәк син.*

***Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, улың Госман, киленең Сания, оныгың Ләйсән.***



Бикүле авылында яшәүче кадерле әтиебез **Мусин Нәбиулла Закир** улына сентябрь аенда 55, сеңлебез **Заһирова Зөлфия Нәбиулла** кызына 19 яшь тула.

Ачык йөзле, мәрхәмәтле әтиебез һәм яраткан сеңлебез! Сезне туган көнегез белән котлыйбыз. Сезгә олы бәхет, нык исәнлек, әтиебезгә әниебез белән, сеңлебезгә тормыш иптәше белән тигез гомер телибез.

Гел шатланып яшәгез сез,
Хәсрәт күрмәгез бердә
Тыныч булсын һәрчак күңелегез,
Бәрәкәтле матур тормыш сезгә.

**Изге теләкләр белән торыш иптәшең, кызларың, кияүләрең, улларың, киленнәрең, оныкларың.**

# МЕНӘ СИҢА МӘ!



Нигерия шәһәрләренең берсендә бер авыруның ашказаныннан 1 килограмм 84 грамм авырлыгындагы 494 металл әйбер алына. Алар арасында 303 кадак, 106 монета, 25 эләктергеч, 18 энә, 6 лезвие һәм башкалар булган.

* * *

Мәскәүдә машина урлау хәзер «индустриаль» нигездә алып барыла. Бу җәһәттән, махсус конторалар ачылган. Клиентлар машинаның маркасын, төсен, эшләнгән вакытын әйтә, бераз аванс түли, калганы - контораның эше. Күп тә үтми, калган акчаны түләп, яңа номерлы, «законлы» документлары булган машинаны ал да элдерт кенә.

* * *

Һиндстанда фил, сыер кебек үк, изге хайван дип исәпләнә. Бигрәк тә шәһәр урамнарында йөрүче филләр. Ләкин соңгы вакытта бу пәһлеваннарга бензин, мазут һәм башка зарарлы матдәләр белән пычранган урамнар буйлап йөрү кыенлаша башлады. Шуңа күрә шәһәр филләренә махсус итекләр тегеп кидерергә карар иткәннәр.

* * *

Көнбатыш Германия шәһәрләренең берсендә бер ханым күп еллар буе балага уза алмый җәфалана. Ниһаять, табиблар тырышлыгы уңыш китерә: хатын берьюлы дүрт игезәк таба.

## Сорау - җавап    Сорау - җавап

# ТӨРЛЕ СУЫТКЫЧ ТӨРЛЕЧӘ САКЛЫЙ

*Суыткычта ничә йолдыз булырга тиеш?*
**Р.Рәхимов.**

Дөрес җавапны коньяктагы кебек: никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшырак. Кызганычка каршы, йолдыз санына карап, суыткычның бәясе дә арта бара. Әгәр экономияләргә теләсәгез, артык йолдызларны сатып алмагыз.

Нинди суыткычны сайлап алырга соң? Әгәр аның корпусында бер йолдыз булса, димәк, туңдыру камерасында минималь температура - минус 6 градус. Туңдырылган азык - төлекне анда атнадан артык сакларга ярамый. Ике йолдыз туңдыргычта минус 12 градус салкынлыкны тәэмин итә. Туңган продуктларны бер ай сакларга була. Өч йолдыз 18 градус салкынлык бирә, димәк, ашамлыкларны анда өч ай буена сакларга мөмкин. Дүрт йолдыз, төгәлрәге, өч кара йолдыз һәм кара фонда бер якты йолдыз камерада 18 градустан да түбәнрәк температура саклау мөмкинлеге бирә. Продуктларны озак вакытларга тупларга яратучылар өчен бик әһәмиятлесе шул - мондый суыткыч ризыкны туңдыруга махсус көйләнгән. Әгәр сез гадәти туңдыргычка (морозилка) берничә килограмм суынып та җитмәгән ит салып куйсагыз, ул әле туңганчы камерага куелган нәрсәләрне эретәчәк. Нәтиҗәдә ипләп төрелгән төрелмәләр урынына сез аннан бер тоташ булып каткан кисәк - кантар алырсыз. Дүрт йолдызлы суыткыч сезне моңардан коткарыр. Аның куәте шундый ки, ул файдалы күләмнең һәр йөз литрына тәүлек саен бернинди зыянсыз 4,5 килограмм продукт туңдыру мөмкинлеге бирә. Дүрт йолдызлыда продуктларны ел буена сакларга мөмкин.

Хәзер инде суыткычның башка сыйдырышлары турында. Югары бүлекләрдә температура Цельсий буенча 0 - 2 градус була. Аларда яңа итне күп дигәндә 4 көн сакларга мөмкин. Фаршны 1 көн, кыздырылган итне - 3 - 4 көн, эчне - бавырны - 1 - 2 көн сакларга була. Эче алынган свежий балыкны 2 көн; әле генә тотылганын 4 көн, кыздырылганын 2 - 3 көн саклый аласың. Эретелгән ризыкларны, әгәр сүз ит, балык яки диңгез ризыклары турында барса, бер көннән артык сакларга ярамый.

Үзәк шүрлекләрдә температура 3 - 5 градус. Сөт ризыклары, әзер ризыклар, кондитер әйберләре өч көн саклана. Гөмбә, әзерләнгән яшелчә - 3 - 5 көн. Ветчина, паштет, эремчек 4 - 6 көн.

Аскы шүрлекләрдә температура 5 - 6 градус. Сыр, яңа җиләк - җимеш бер атна саклана анда. Яшелчә аслыгында 7 градус. Анда яшелчәләрне бер атна саклап була. Ишек шүрлекләрендә температура 6 - 8 градус. Ачылмаган атланмай брикеты анда өч атна, башланганы бер атна саклана. Йомырка бер атна, ачылган сөт - 4 көн.

Әгәр суыткычтан тәмсез ис сизелә башласа, аскы киштәгә ярты лимон куегыз. Ул төрле исләрне үзенә туплар.

Йомырканы очлы ягын аска каратып тезегез. Шулай иткәндә йомырка сарысы аның кабыгына орынмас, ә аның тишекләрне аша кайчак бактерияләр дә керергә мөмкин бит.

Ачык рәвештә уылдык өч көннән артык саклана алмый. Майонез тибындагы соуслар банкыны ачканнан соң айдан артык, кетчуп һәм томат пастасы ике айдан артык сакланырга тиеш түгел.


# Белдерүләр

## САТАБЫЗ

**Дружба урамында 70 нче йортта 45 нче номерлы 2 бүлмәле фатир.** 16.00 сәг.тән 20 сәг. кә кадәр мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**Ашыгыч төстә әйбәт хәлдәге УАЗ - 469, (бәясе - 13 млн. сум) һәм 1993 елгы ВАЗ - 2104.** Самара өлкәсе, Кошки авылы, 4 квартал, 5 нче йорт, 10 нчы фатирга яки 2 - 31 - 30 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**Гараж капкасы**. Тел.: 5 - 26 - 56.

* * *

**Сүтү өчен 3,5 х 10 метрлы йорт.** Тел.: 5 - 18 - 09.

* * *

**1997 елгы ВАЗ - 21083 сатыла яки 1 бүлмәле фатирга алыштырыла.** Тел.: 5 - 21 - 94.

* * *

**5 х 10 метрлы әйбәт хәлдәге йорт**. Полевая ур., 22 йортка мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**1993 елгы ВАЗ - 2107 машинасы.** Адрес: Дружба ур., 74 - 27, тел. 65 - 7 - 29, (17.00 сәг. тән соң).

* * *

**Әйбәт хәлдәге ГАЗ - 52**. Тел.: 5 - 18 - 21. ( 16 сәг. соң).

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**ВАЗ автомашинасын «Газпром» РАО сы акцияләренә**. Тел.: 5 - 36 - 60 (14.00 сәг.тән 16.00 сәг.кә кадәр).

* * *

**Циолковский урамында 11 йортта 10нчы номерлы 2 бүлмәле фатирны - ике берәр бүлмәлегә.** Адрес:Циолковский ур., 9 - 50 (17.00 сәг.тән соң)

## ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ

**«Н.Октябрь АТП»сы АҖсенә ашыгыч рәвештә**
**- «С», «Д» категорияле шоферлар,**
**- 4 - 5.разрядлы токарь,**
**- котельня операторы.**

* * *

**Октябрь юл участогына машинист - экскаваторчы кирәк.**

* * *

**«Татнефть - Норлатнефтеразведка» ОООсына даими эшкә АЗ - 5, КП - 25 трактор краннарына машинистлар кирәк. Белешмәләр өчен кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә.** Тел.: 2 - 29 - 13.

* * *

**«Н.Октябрь сәүдә базасы» АООТына ашыгыч рәвештә даими эшкә**
**- газ рәвешле ягулыкта эшләүче пар казаннары операторы;**
**- газ хуҗалыгы өчен җаваплы квалификациясе һәм 2 елдан ким булмаган стажлы котельня начальнигы.**

### *Идел Буе региональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 26 сентябрь, 10 октябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


Октябрь урман хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлеге коллективы улы **Ленарның** вакытсыз фаҗигале үлүе сәбәпле Әюпова Нурисә Исхаковнаның тирән кайгысын уртаклаша.

Норлат җылылык челтәре предприятиесе әтисе **Вәгыйзь Минхәер** улы үлүе сәбәпле, Мингалимов Вәли Вәгыйзь улының авыр хәсрәтен уртаклаша.

Дусларыбыз Салих Мингалимович һәм Нурисә Исхаковна Әюповларның сөекле уллары **Ленарны** югалту кайгысын чын күңелдән уртаклашабыз.

Әюповлар, Гыйрфановлар, Хөсәеновлар.

«Норлатнефть» УТТсы админстрациясе, профсоюз комитеты **әтиләре** һәм **бабалары** үлү сәбәпле күтәрткеч машинисты Петровский Сергей Вацлович, шәфкать туташы Петровская Елена Вацловна һәм I нче автоколонна шоферы Рязанов Константин Николаевичның тирән кайгысын уртаклаша.

«Норлатнефть» УТТсы администрациясе, профсоюз комитеты **әтисенең** вакытсыз үлүе сәбәпле күтәрткеч машинисты Спиченков Александр Ефимовичның авыр хәсрәтен уртаклаша.

«Норлатнефть» УТТсы администрациясе, профсоюз комитеты **улының** фаҗигале үлүе сәбәпле күтәрткеч машинисты Идрисов Минвазыйх Вәгыйзь улының авыр кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә.